КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 22 октябрь г.Казань № 952

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республи-касының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 ноябрь, 1036 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 52 нче; 2013 ел, 29 июнь, 458 нче; 2014 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы; 2014 ел, 15 февраль, 91 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 29 июль, 553 нче; 2014 ел, 2 август, 565 нче; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 22 октябрь, 775 нче; 2015 ел, 2 апрель, 209 нчы; 2015 ел, 22 июль, 536 нчы; 2015 ел, 3 ноябрь, 833 нче; 2016 ел, 26 май, 356 нчы; 2016 ел, 30 июнь, 449 нчы; 2017 ел, 16 март, 144 нче; 2017 ел, 20 июнь, 400 нче; 2017 ел, 5 сентябрь, 636 нчы; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2018 ел, 14 июнь, 482 нче; 2018 ел, 15 июнь, 486 нчы; 2018 ел, 16 ноябрь, 998 нче; 2019 ел, 17 июль, 594 нче; 2019 ел, 28 август, 715 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Комплекслы реабилитация буенча белгеч (реабилитолог)» вазыйфасын биләүче, югары һөнәри белемле, аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификациясен бирүне раслый торган хезмәткәрләрнең база өлеше – 18 495 сум.»;

6.2 пунктта «гаилә белән эшләү буенча белгеч» сүзләреннән соң «, комплекслы реабилитация буенча белгеч (реабилитолог)» сүзләрен өстәргә;

6.8.9 пунктның 19 таблицасындагы 2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2. | «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә өченче дәрәҗәдәге белгечләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| 2.1. | Инвалидларга һөнәри юнәлеш бирү буенча белгеч | 50 |
| 2.2. | Социаль эш буенча белгеч | 50 |
| 2.3. | Гаилә белән эшләү буенча белгеч | 50 |
| 2.4. | Дәвалау физкультурасы буенча инструктор-методист | 50 |
| 2.5. | Медицина психологы | 55 |
| 2.6. | Инвалидларны тернәкләндерү буенча белгеч | 55 |
| 2.7. | Комплекслы реабилитация буенча белгеч (реабилитолог) | 55 |
| 2.8. | Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары буенча инженер | 55 |
| 2.9. | Консультант по профессиональной реабилитации инвалидов | 60»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларына һәм эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

1 нче кушымтада:

2.2 пунктчада «няня» һәм «хуҗа-туташ» сүзләрен «няня», «хуҗа-туташ» һәм «сиделка» сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктчада «няня» һәм «хуҗа-туташ» сүзләрен «няня», «хуҗа-туташ» һәм «сиделка» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктчада «няня» һәм «хуҗа-туташ» сүзләрен «няня», «хуҗа-туташ» һәм «сиделка» сүзләренә алмаштырырга;

9.2 пунктчада «няня» һәм «хуҗа-туташ» сүзләрен «няня», «хуҗа-туташ» һәм «сиделка» сүзләренә алмаштырырга;

10.2 пунктчада «няня» һәм «хуҗа-туташ» сүзләрен «няня», «хуҗа-туташ» һәм «сиделка» сүзләренә алмаштырырга;

3 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Административ - хуҗалык белән тәэмин итү буенча белгеч; офис-менеджер | урта һөнәри белем-урта буын белгечләрен әзерләү программасы; өстәмә һөнәри белем бирү-эшчәнлек профиле буенча һөнәри әзерлек программалары | склад мөдире, хуҗалык мөдире | 8 893,0 |
| Административ-хуҗалык бүлеге җитәкчесе; административ-хуҗалык бүлеге башлыгы | югары белем-бакалавриат; югары белем (профильсез) – бакалавриат; өстәмә һөнәри белем-эшчәнлек юнәлеше буенча яңадан һөнәри әзерлек программасы | хуҗалык бүлеге башлыгы | 9 071,0 |
| Сиделка (тәрбияләү буенча ярдәмче) | һөнәри белем бирүнең төп программалары – хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары | няня | 8 380,0». |

2. Бу карарның гамәле 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин